Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Рус Шаршадысы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**30.10.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 30 октябрендә 14 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; ( су башнясын карап тоту, хезмәт күрсәтү, кирәкле материаллар сатып алу,торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3) Зират коймаларын ремонтлау, төзекләндерү (православие зиратына койма кою өчен материаллар сатып алу һәм эшләтү).

4) Торак пунктын төзекләндерү (Рус Шаршадысы авылының Кыр урамын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча трактористка түләү; башка чыгымнар).

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 34 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 19 кеше, бу 54,8% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 19 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Iтөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; ( су башнясын карап тоту, хезмәт күрсәтү, кирәкле материаллар сатып алу,торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын

һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3) Зират коймаларын ремонтлау, төзекләндерү (православие зиратына койм кою өчен материаллар сатып алу һәм эшләтү).

4) Торак пунктын төзекләндерү (Рус Шаршадысы авылының Кыр урамы кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм хезмәт килешу буенча трактористка түләү; башка чыгымнар).

4.Карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарста Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикас Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтынд (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникаци челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталынд (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Ә.Р. Төхфәтуллин